ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10 ноябрь 2020 ел № 5888

**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең социаль стандартын раслау турында**

Яр Чаллы муниципаль берәмлеге территориясендә халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне яхшырту максатында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1 бүлегенең 7 пунктчасы, Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының 2017 елның 31 гыйнварындагы НА-19-р номерлы боерыгы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең социаль стандартын кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2020 елның 10 ноябрендәге
5888 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең социаль стандарты

1. Автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең әлеге социаль стандарты (алга таба – стандарт) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими йөртү муниципаль маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең дәрәҗәсен, сыйфат күрсәткечләрен һәм аларның норматив зурлыкларын билгели.

Әлеге стандартта халыкка транспорт хезмәте күрсәтү дигәндә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими пассажирлар йөртү маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру буенча эшләр башкару аңлашыла. Халыкка транспорт хезмәте күрсәтү сыйфаты автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими йөртү маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда халыкка транспорт хезмәте күрсәтү дәрәҗәсен интеграль бәяләүдән гыйбарәт һәм ышанычлылык, файдалана алырлык булу һәм комфортлылык характеристикалары җыелмасында чагыла.

2. Халыкка транспорт хезмәте күрсәтү сыйфаты күрсәткечләре һәм аларның әлеге стандартта билгеләнгән норматив күрсәткечләре даими тарифлар буенча даими пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле эшләрне башкаручы муниципаль заказчылар, юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр белән муниципаль контрактлар төзегәндә һәм башкарганда кулланыла ала.

3. Сыйфат күрсәткечләре һәм аларның норматив зурлыклары.

1) Файдалана алырлык булу.

Файдалана алырлык булу дигәндә, автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими йөртү маршрутлары буенча халыкның пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча хезмәтләр алу мөмкинлеге булуда чагыла торган халыкка транспорт хезмәте күрсәтү сыйфаты характеристикасы аңлашыла;

2) тукталыш пунктларының территориаль файдалана алырлык булуы.

Объект урнашкан участокның, автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча хезмәт күрсәтелә торган иң якындагы тукталыш пунктына кадәр иң кыска җәяүлеләр йөрү юлының арасы, табигый һәм ясалма каршылыкларны исәпкә алып, объектларның категорияләренә бәйле рәвештә, 1 нче таблицада күрсәтелгән зурлыклардан артмый.

Иң кыска җәяүлеләр юлының объектларның участок чикләреннән тукталыш пунктларына кадәр чик озынлыгы

1 таблица

| Объектның категориясе | Иң кыска җәяүлеләр юлының озынлыгы, артык түгел, м |
|---|---|
| Күпфатирлы йорт | 500 |
| Шәхси торак йорт | 800 |
| Объектның категориясе | Иң кыска җәяүлеләр юлының озынлыгы, артык түгел, м |
| Сәүдә залы 1000 кв.м һәм аннан артык булган сәүдә предприятиесе | 500 |
| Муниципаль, региональ һәм федераль сәламәтлек саклау системасы поликлиникалары һәм хастаханәләре, гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре (бүлекчәләре) | 300 |
| Тышкы транспорт терминаллары | 300 |

3) Даими йөртү муниципаль маршрутлары буенча йөрү бәяләренең түли алырлык булуы.

Муниципаль берәмлек чикләрендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими йөртү муниципаль маршрутлары буенча йөрүләрне гамәлгә ашыруга пассажирның уртача айлык чыгымнары муниципаль берәмлек урнашкан Россия Федерациясе субъектында халыкның җан башына исәпләнгән уртача арифметик акчалата кереме күләменең 7% нан артмый. Муниципаль берәмлек урнашкан Россия Федерациясе субъектында халыкның җан башына исәпләнгән уртача арифметик акчалата керем күләме Россия Федерациясенең күрсәтелгән субъектында халыкның җан башына уртача акчалата кереме дәрәҗәсеннән түбәнрәк булган җан башына уртача акчалата керемнәре күләме буенча халыкны бүлүдә җан башына уртача акчалата керемнәр интерваллары өчен түбәндәге формула нигезендә исәпләнә:

$$СД_{взв} = \frac{\sum Д_I * w_i}{\sum w_i},$$

монда:

$СД_{взв}$ - муниципаль берәмлек урнашкан Россия Федерациясе субъектында халыкның җан башына исәпләнгән уртача акчалата кеременең уртача арифметик күләме;

$Д_I$ - муниципаль берәмлек урнашкан Россия Федерациясе субъектында җан башына уртача акчалата керемнәр күләме буенча халыкны бүлүдә халыкның тиешле өлеше белән җан башына уртача акчалата керем интервалында җан башына уртача акчалата керемнең медиана күләме;

$W_i$ - муниципаль берәмлек урнашкан Россия Федерациясе субъекты халкының җан башына уртача акчалата керем күләме Россия Федерациясенең күрсәтелгән субъектында җан башына уртача акчалата керемнән түбәнрәк булган өлеше.

Автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими йөртү маршрутлары буенча йөрүләр өчен пассажирның уртача айлык чыгымнары күләме автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими йөртү маршрутлары буенча йөрүләр өчен ай дәвамында чикләнмәгән санда йөрү хокукы бирүче

озак файдаланыла торган билет бәясенә тиңләштерелә, әгәр дә җайга салынмый торган тарифлар буенча даими йөртү маршрутларының өлеше әлеге муниципаль берәмлектә даими йөртү муниципаль маршрутларының гомуми санынннан 25% тан артык булмаса.

Муниципаль берәмлектә даими йөртү маршрутлары буенча автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында йөрү өчен ай дәвамында чикләнмәгән санда йөрү хокукы бирүче озак вакыт кулланыла торган билетлар булмаган яки җайга салынмый торган тарифлар буенча даими йөртү маршрутларының рейслар саны муниципаль берәмлектә даими йөртү маршрутлары рейсларының гомуми санынннан 25% ка арткан очракта, муниципаль берәмлек чикләрендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими йөртү маршрутлары буенча йөрү өчен пассажирның уртача айлык чыгымнары күләме автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими йөртү муниципаль маршрутлары буенча пассажир тарафыннан гамәлгә ашырыла торган йөрүләр (шул исәптән аерым йөрүләр буларак күчеп утырулар) санының бәясе кебек, түбәндәге формула нигезендә исәпләнә:

$$P = C * q,$$

монда:

C - автомобиль транспортында яисә шәһәр җир өсте электр транспортында даими йөртү муниципаль маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда автомобиль транспортында яисә шәһәр җир өсте электр транспортында бер тапкыр йөрүнең уртача бәясе, сумнарда;

q – муниципаль берәмлекнең халык санынннан чыгып, автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими йөртү муниципаль маршрутлары буенча пассажирлар тарафыннан гамәлгә ашырыла торган йөрүләр (шул исәптән күчереп утырулар) саны.

Автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими йөртү муниципаль маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында бер тапкыр йөрүнең уртача бәясе түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$C = \frac{Q_{рег} * C_{рег} + Q_{нер1} * C_{нер1} + Q_{нер2} * C_{нер2} + \ldots + Q_{нерn} * C_{нерn}}{Q_{рег} + Q_{нер1} + Q_{нер1} + \ldots + Q_{нерn}}$$

монда:

$Q_{рег}$ - автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында җайга салына торган тарифлар буенча даими пассажирлар йөртү һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары рейслары саны;

$C_{рег}$ - автомобиль транспортында яисә шәһәр җир өсте электр транспортында җайга салына торган тарифлар буенча даими йөртү муниципаль маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда автомобиль транспортында яисә шәһәр җир өсте электр транспортында бер тапкыр йөрү бәясе;

$Q_{нерn}$ - автомобиль транспортында тиешле тариф нигезендә җайга салынмый торган тарифлар буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары рейслары саны;

$C_{нерn}$ - автомобиль транспортында пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны муниципаль маршрутлар буенча тиешле тариф нигезендә җайга салынмый торган тарифлар буенча гамәлгә ашырганда автомобиль транспортында бер тапкыр йөрү бәясе;

Чаллы шәһәре халкы өчен автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында билгеләнгән вакыт дәвамында чикләнмәгән санда йөрү хокукы бирә торган даими йөртү муниципаль маршрутлары буенча йөрүне гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирүче озак файдаланыла торган билет булу мәҗбүри.

4) халыкның аз мобильле төркемнәре өчен транспорт чараларының файдалана алырлык булуы.

Автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими йөртү маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру өчен файдаланыла торган барлык транспорт чараларында йөртүче тарафыннан утырту һәм төшерү, шул исәптән инвалид пассажирлар өчен автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты транспорт чаралары, автовокзаллар, автостанцияләр һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән файдалана алырлык булу шартлары, шулай ук бу вакытта аларга кирәкле ярдәм күрсәтү тәртибе нигезендә, мөстәкыйль хәрәкәт итә алмый торган инвалид пассажирлар өчен махсус күтәртү җайланмаларын кулланып, тәэмин ителергә тиеш.

5) Ышанычлылык.

Ышанычлылык ул автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими йөртү маршрутлары буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча хезмәтләр алуның тотрыклылыгында һәм аның сыйфат дәрәҗәсе алдан фаразлануында чагыла торган халыкка транспорт хезмәте күрсәтү сыйфатының характеристикасыннан гыйбарәт.

6) Даими йөртү маршрутлары расписаниесен үтәү.

Һәр тукталыш пунктыннан, автовокзалдан һәм автостанциядән даими йөртү маршрутының һәр рейсы билгеләнгән расписание буенча яисә расписаниедә күрсәтелгән вакыттан ике минут алдан я ике минутка соңрак гамәлгә ашырыла. Ике минуттан артык соңга калып башкарылган даими йөртү рейсларының саны тиешле тәрдәге даими йөртү маршрутлары рейсларының гомуми санынан 15% тан артмый.

7) Комфортлылык.

Комфортлылык дигәндә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими йөртү маршрутлары буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча хезмәт күрсәтүләрдән файдалануның уңайлылыгы дәрәҗәсендә, шул исәптән хезмәт күрсәтү процессында пассажирлар өчен физиологик һәм психологик дискомфорт булмауда чагыла торган халыкка транспорт хезмәте күрсәтү сыйфатының характеристикасы аңлашыла.

8) Транспорт чараларының пассажирларга хәбәр итү чаралары белән җиһазландырылуы.

Автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими йөртү маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру өчен файдаланыла торган барлык транспорт чаралары Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар һәм багаж йөртү кагыйдәләрен раслау турында» 2009 елның 14 февралендәге 112 номерлы (21.02.2020 ред.) карарының 32, 36 пунктлары һәм 37 пунктының «а», «б», «г» пунктчалары нигезендә пассажирларга хәбәр итү чаралары белән җиһазландырыла.

9) Транспорт чаралары салонындагы температура.

Автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими йөртү маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру өчен файдаланыла торган барлык транспорт чаралары елның теләсә кайсы вакытында транспорт чарасы салонында комфортлы температураны саклауга көйләнгән җылылык һәм һаваны кондиционерлаштыру системалары белән җиһазландырылган. Температура режимы: тышта уртача тәүлеклек һава температурасы 5°С дан ким булганда - 12°С дан ким түгел, тышта уртача тәүлеклек һава температурасы 20°С дан югарырак булганда - 25°С дан артык түгел.

10) Сыйдырышлылык нормаларын үтәү.

Автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими йөртүнең муниципаль һәм муниципальара маршрутлары буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өчен файдаланыла торган транспорт чарасының факттагы тулылыгы транспорт чарасы салоны идәнендә басып баручы пассажирлар өчен каралган буш

мәйданның 1 квадрат метрына биш кешедән дә артмый. Автомобиль транспортында даими йөртүләрнең арадаш, региоонара һәм халыкара маршрутлары буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташу утыра торган урыннарны файдаланып кына гамәлгә ашырыла.

11) Күчеп утырулар саны.

Халык саны 500 000 нән артык булган муниципаль берәмлекнең теләсә кайсы ноктасына бару максатында даими йөртүләрнең муниципаль һәм муниципальара маршрутларыннан файдаланганда, пассажир тарафыннан гамәлгә ашырыла торган күчеп утыруларның гомуми саны икедән артмый.

12) Экологиялелек.

Автомобиль транспортында даими йөртү маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру өчен файдаланыла торган барлык транспорт чаралары «Евро-4» һәм аннан югарырак экологик класска карый.

13) Транспорт чарасының җитештерүче - завод тарафыннан билгеләнгән хезмәт итү срогы артып китү.

Автомобиль транспортында даими йөртү маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру өчен файдаланыла торган барлык транспорт чаралары да билгеләнгән хезмәт итү срогы артып китмәгән транспорт чараларына керә. Хезмәт итү срогы турында мәгълүмат транспорт чарасының документларында бирелә. Җитештерүче завод хезмәт итү срогын күрсәтмәгән очракта, «Кулланучылар хокукларын яклау турында» Федераль законның 6 статьясы нигезендә, аны транспорт чарасы кулланучыга тапшырылган көннән башлап 10 ел итеп кабул итәләр.

4. Стандарт таләпләренә туры килүне бәяләү автомобиль транспортында даими йөртү муниципаль маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда халыкка транспорт хезмәте күрсәтү дәрәҗәсенең интеграль күрсәткечен кулланып үткәрелә, ул автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда халыкка транспорт хезмәте күрсәтү (кушымта), шулай ук автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда халыкка транспорт хезмәте күрсәтү сыйфатын бәяләү методикасы нигезендә, шулай ук автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча хезмәтләрдән канәгать булу дәрәҗәсе турында халыктан сораштырулар нигезендә үткәрелә.

Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе урынбасары, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы

А.Ф. Бареева

Автомобиль транспортында
һәм шәһәр җир өсте электр транспортында
пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны
гамәлгә ашырганда халыкка
транспорт хезмәте күрсәтүнең
социаль стандартына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын бәяләү методикасы

1. Халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын билгеләгәндә файдаланыла торган күрсәткечләр хисап чоры (календарь ел) өчен исәпләнә.

2. Транспорт хезмәте күрсәтүнең файдалана алырлык булуы түбәндәге күрсәткечләр ярдәмендә бәяләнә:

- аз мобильле төркемнәр өчен транспорт чараларының файдалана алырлык булу коэффициенты;

- тукталыш пунктларының территориаль файдалана алырлык булу коэффициенты;

- даими йөртү маршрутлары буенча йөрүләрнең бәясе түли алырлык булу.

1) Аз мобильле төркемнәр өчен транспорт чараларының файдалана алырлык булу коэффициенты түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$k_{\text{тс.мгн}} = \frac{Q_{\text{тс.мгн}}}{Q_{\text{тс}}},$$

монда:

$К_{\text{тс.мгн}}$ –кресло-арбада утыручы кешене транспорт чарасына утыртканда яки аннан төшергәндә күчереп кую өчен ярдәмче чаралар белән җиһазландырылган транспорт чараларының саны;

$Q_{\text{тс.мгн}}$ – автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими йөртү маршрутлары буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өчен билгеләнгән транспорт чараларының гомуми саны, берәмлек.

Күрсәткечнең зурлык интервалына карап, аңа әлеге методиканың 1 нче таблицасы нигезендә балл бирелә.

Халыкның аз мобильле төркемнәре өчен транспорт чараларының файдалана алырлык булу коэффициенты зурлыкларын бәяләү

1 таблица

| Халыкның аз мобильле төркемнәре өчен транспорт чараларының файдалана алырлык булу коэффициенты зурлыгы | Балл ($К_{\text{тс.мгн}}$) |
|---|---|
| < 0,1 | 1 |
| ≥ 0,1 | 2 |
| ≥ 0,2 | 3 |
| ≥ 0,3 | 4 |

| | |
|---|---|
| ≥ 0,4 | 5 |
| ≥ 0,5 | 6 |
| ≥ 0,6 | 7 |
| ≥ 0,7 | 8 |
| ≥ 0,8 | 9 |
| ≥ 0,9 | 10 |

2) Тукталыш пунктларының территориаль файдалана алырлык булу коэффициенты түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$k_{дост} = \frac{Q_{мкд.дост} + Q_{ид.дост} + Q_{тп.дост} + Q_{мед.дост} + Q_{вн.тр.дост}}{Q}$$

монда:

$Q_{мкд.дост}$ - объект урнашкан җир участогы чигенең якындагы тукталыш пунктына кадәр иң якын ноктасыннан иң кыска җәяүлеләр йөрү юллары арасының норматив зурлыклары чикләрендә урнашкан тукталыш пунктлары саны, берәмлек;

$Q_{ид.дост}$ - тукталыш пунктларына кадәр җәяү бару нормативы чикләрендәге шәхси йортлар саны, берәмлекләр;

$Q_{тп.дост}$ - тукталыш пунктларына кадәр җәяү бару нормативы чикләрендә сәүдә залының мәйданы 1000 кв.м һәм аннан артык булган сәүдә предприятиеләренең саны, берәмлек;

$Q_{МЕД.ДОСТ}$ – тукталыш пунктларына кадәр җәяү бару нормативы чикләрендә муниципаль, региональ һәм федераль сәламәтлек саклау системасы поликлиникалары һәм хастаханәләре, гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре (бүлекчәләре) саны, берәмлек;

$Q_{вн.тр.дост}$ - тукталыш пунктларына кадәр җәяү бару нормативы чикләрендә тышкы транспорт терминалларының саны, берәмлек;

Q - тукталыш пунктларының гомуми саны, берәмлек.

Күрсәткечнең зурлык интервалына карап, аңа әлеге методиканың 2 нче таблицасы нигезендә балл бирелә.

Тукталыш пунктларының территориаль файдалана алырлык булу коэффициенты зурлыкларын бәяләү

2 таблица

| Тукталыш пунктларының территориаль файдалана алырлык булу коэффициенты зурлыгы | Балл ($K_{дост}$) |
|---|---|
| ≥ 0 | 1 |
| ≥ 0,1 | 2 |
| ≥ 0,2 | 3 |
| ≥ 0,3 | 4 |
| ≥ 0,4 | 5 |
| ≥ 0,5 | 6 |

| | |
|---|---|
| ≥ 0,6 | 7 |
| ≥ 0,7 | 8 |
| ≥ 0,8 | 9 |
| ≥ 0,9 | 10 |

3) Даими йөртү маршрутлары буенча йөрүләрнең бәясе түли алырлык булу коэффициенты түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$k_{д} = \frac{P}{СДвзв},$$

монда:

P - муниципаль берәмлек чикләрендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими йөртү муниципаль маршрутлары буенча йөрүләрне гамәлгә ашыруга пассажирның уртача айлык чыгымнары;

$СД_{ВЗВ}$ - муниципаль берәмлек урнашкан Россия Федерациясе субъектында халыкның җан башына исәпләнгән уртача акчалата кеременең уртача арифметик күләме, сум.

Күрсәткечнең зурлык интервалына карап, аңа әлеге методиканың 3 нче таблицасы нигезендә балл бирелә.

Даими йөртү маршрутлары буенча йөрүләрнең бәясе түли алырлык булу коэффициенты зурлыкларын бәяләү

3 таблица

| Тукталыш пунктларының территориаль файдалана алырлык булу коэффициенты зурлыгы | Балл ($К_Д$) |
|---|---|
| 0,02 дән кимрәк һәм 0,07 дән күбрәк | 1 |
| 0,02дән 0,03кә кадәр һәм 0,06 дан 0,07гә кадәр | 4 |
| 0,03тән 0,04кә кадәр һәм 0,05 тән 0,06га кадәр | 7 |
| 0,04 тән 0,05кә кадәр | 10 |

3. Транспорт хезмәте күрсәтүнең ышанычлылыгы җайга салына торган йөртү маршрутлары расписаниесен үтәү коэффициенты күрсәткече белән бәяләнә.

1) Җайга салына торган йөртү маршрутлары расписаниесен үтәү коэффициенты түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$k_{расп} = \frac{Q_{рейс_{расп}}}{Q_{рейс}},$$

монда:

$Q_{рейс.расп}$ - автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими йөртү маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда расписание буенча билгеләнгән вакытка үтәлгән яки хәрәкәт расписаниесеннән рөхсәт ителгән тайпылу чикләрендәге рейслар саны, рейслар.

Автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими йөртүнең муниципаль, муниципальара һам халыкара маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда халыкка транспорт хезмәте күрсәтү

социаль стандартының 4.2.1 пункты нигезендә билгеләнә;

$Q_{рейс}$ – автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими йөртү маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда рейсларның гомуми саны, рейслар.

Күрсәткечнең зурлык интервалына карап, аңа әлеге методиканың 4 нче таблицасы нигезендә балл бирелә.

Даими йөртү маршрутлары расписаниесен үтәү коэффициенты зурлыкларын бәяләү

4 таблица

| Даими йөртү маршрутлары расписаниесен үтәү коэффициенты зурлыгы | Балл ($К_{расп}$) |
|---|---|
| < 0,65 | 1 |
| ≥ 0,65 | 2 |
| ≥ 0,70 | 3 |
| ≥ 0,75 | 4 |
| ≥ 0,80 | 5 |
| ≥ 0,85 | 6 |
| ≥ 0,88 | 7 |
| ≥ 0,90 | 8 |
| ≥ 0,93 | 9 |
| ≥ 0,95 | 10 |

4. Транспорт хезмәте күрсәтүнең комфортлылыгы түбәндәге күрсәткечләр ярдәмендә бәяләнә:

- транспорт чараларының пассажирларга хәбәр итү чаралары белән җиһазландырылу коэффициенты;
- транспорт чарасы салонында норматив температура булган рейслар өлеше;
- сыйдырышлылык нормаларын үтәү коэффициенты;
- югары экологик класслы транспорт чараларының өлеше.

1) Транспорт чараларының пассажирларга хәбәр итү чаралары белән җиһазландырылу коэффициенты түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$k_{оснащ.тс} = \frac{Q_{оснащ.тс}}{Q_{тс}},$$

монда:

$Q_{оснащ.тс}$ - автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими йөртү маршрутлары буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өчен билгеләнгән, Автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртү һәм багаж ташу кагыйдәләренең 32, 36 пунктлары һәм 37 пунктның «а», «б», «г» пунктчалары нигезендә пассажирларга хәбәр итү чаралары белән тәэмин ителгән транспорт чараларының саны, берәмлек:

$Q_{тс}$ - автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими

йөртү маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән транспорт чараларының саны, берәмлек.

Күрсәткечнең зурлык интервалына карап, аңа әлеге методиканың 5 нче таблицасы нигезендә балл бирелә.

Транспорт чараларының пассажирларга хәбәр итү чаралары белән җиһазландырылу коэффициенты зурлыкларын бәяләү

5 таблица

| Транспорт чараларының пассажирларга хәбәр итү чаралары белән җиһазландырылу коэффициенты зурлыклары | Балл ($К_Д$) |
|---|---|
| < 0,1 | 1 |
| ≥ 0,1 | 2 |
| ≥ 0,3 | 4 |
| ≥ 0,4 | 6 |
| ≥ 0,5 | 8 |
| ≥ 0,7 | 9 |
| ≥ 0,9 | 10 |

2) Транспорт чарасы салонында норматив температура булган рейслар өлеше түбәндәге формула белән исәпләнә:

$$Д_{рейс.темп} = (Д_{конд} * Д_{дней>20} + Д_{отопл} * Д_{дней<20 и >5}) * 100,$$

монда:

$Д_{конд}$ –урамда уртача тәүлеклек температура 20°С тан артык булмаганда салонда норматив температура булган, даими маршрутлар буенча халыкка транспорт хезмәте күрсәтүгә җәлеп ителгән рейслар өлеше;

$Д_{отопл}$ – урамда уртача тәүлеклек температура 5°С тан ким булганда салонда норматив температура булган, даими маршрутлар буенча халыкка транспорт хезмәте күрсәтүгә җәлеп ителгән транспорт чараларының өлеше;

$Д_{дней>20}$ – елда уртача тәүлеклек температура 25°С тан артык булган көннәрнең өлеше;

$Д_{дней<5}$ – елда уртача тәүлеклек температура 5°С тан артык, әмма 20°С тан ким булган көннәрнең өлеше.

Күрсәткечнең зурлык интервалына карап, аңа әлеге методиканың 6 нчы таблицасы нигезендә балл бирелә.

Транспорт чарасы салонында норматив температура булган рейслар өлеше зурлыкларын бәяләү (%)

6 таблица

| Транспорт чарасы салонында норматив температура булган рейслар өлеше зурлыгы | Балл ($Д_{рейс.темп}$) |
|---|---|
| < 10 | 1 |
| ≥ 10 | 2 |

| | |
|---|---|
| ≥ 20 | 3 |
| ≥ 30 | 4 |
| ≥ 40 | 5 |
| ≥ 50 | 6 |
| ≥ 60 | 7 |
| ≥ 70 | 8 |
| ≥ 80 | 9 |
| ≥ 90 | 10 |

3) Сыйдырышлылык нормалары үтәлү коэффициенты түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$k_{вм} = \frac{Q_{рейс_{вм}}}{Q_{рейс}},$$

монда:

$Q_{рейс.вм}$ – автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими йөртү маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда сыйдырышлылык нормалары үтәлә торган рейсларның саны, рейслар.

Автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими йөртү маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда халыкка транспорт хезмәте күрсәтү социаль стандартының 4.3.4. пункты нигезендә билгеләнә.

$Q_{рейс}$ - автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими йөртү маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда башкарылган рейсларның гомуми саны, рейслар.

Күрсәткечнең зурлык интервалына карап, аңа әлеге методиканың 7 нче таблицасы нигезендә балл бирелә.

Сыйдырышлылык нормалары үтәлү
коэффициенты зурлыкларын бәяләү

7 таблица

| Сыйдырышлылык нормалары үтәлү коэффициенты зурлыгы | Балл ($К_{ВМ}$) |
|---|---|
| < 0,1 | 1 |
| ≥ 0,1 | 2 |
| ≥ 0,2 | 3 |
| ≥ 0,3 | 4 |
| ≥ 0,4 | 5 |
| ≥ 0,5 | 6 |
| ≥ 0,6 | 7 |

| | |
|---|---|
| ≥ 0,7 | 8 |
| ≥ 0,8 | 9 |
| ≥ 0,9 | 10 |

4) Күчеп утыру коэффициенты түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$k_{пересад} = \frac{N_{пересад_{норм}}}{N_{пересад}},$$

монда:

$N_{пересад.норм}$ - даими йөртүләрнең муниципаль һәм муниципальара маршрутларыннан файдаланганда, муниципаль берәмлекнең теләсә кайсы ноктасына бару максатында бер йөрү кысаларында норматив күчеп утырулар санын гамәлгә ашыра торган пассажирлар саны, кеше.

Автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими йөртү маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда халыкка транспорт хезмәте күрсәтү социаль стандартының 4.3.5 пункты нигезендә билгеләнә.

$N_{пересад}$ - даими йөртүләрнең муниципаль һәм муниципальара маршрутларыннан файдаланганда, муниципаль берәмлекнең теләсә кайсы ноктасына бару максатында бер йөрү кысаларында күчеп утыруларны гамәлгә ашыра торган пассажирларның гомуми саны, кеше.

Күрсәткечнең зурлык интервалына карап, аңа әлеге методиканың 8 нче таблицасы нигезендә балл бирелә.

Күчеп утырулар саны буенча нормалар үтәлү коэффициенты зурлыкларын бәяләү

8 таблица

| Күчеп утырулар саны буенча нормалар үтәлү коэффициенты зурлыгы | Балл ($K_{пересад}$) |
|---|---|
| < 0,1 | 1 |
| ≥ 0,1 | 2 |
| ≥ 0,2 | 3 |
| ≥ 0,3 | 4 |
| ≥ 0,4 | 5 |
| ≥ 0,5 | 6 |
| ≥ 0,6 | 7 |
| ≥ 0,7 | 8 |
| ≥ 0,8 | 9 |
| ≥ 0,9 | 10 |

5) Югары экологик класслы транспорт чараларының өлеше түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$Д_{эко} = \frac{Q_{TC_{эко}}}{Q_{TC}} \times 100(\%),$$

монда:

$Q_{тс.эко}$ – автомобиль транспортында даими йөртү маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән «Евро-4» һәм аннан да югары экологик класслы транспорт чараларының саны, берәмлек;

$Q_{тс}$ – автомобиль транспортында даими йөртү маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән транспорт чараларының саны, берәмлек.

Күрсәткечнең зурлык интервалына карап, аңа әлеге методиканың 9 нчы таблицасы нигезендә балл бирелә.

Югары экологик класслы транспорт чаралары
өлешенең зурлыкларын бәяләү (%)

9 таблица

| Югары экологик класслы транспорт чаралары өлешенең зурлыгы(%) | Балл ($Д_{эко}$) |
|---|---|
| $< 10$ | 1 |
| $\geq 10$ | 2 |
| $\geq 20$ | 3 |
| $\geq 30$ | 4 |
| $\geq 40$ | 5 |
| $\geq 50$ | 6 |
| $\geq 60$ | 7 |
| $\geq 70$ | 8 |
| $\geq 80$ | 9 |
| $\geq 90$ | 10 |

5. Транспорт чарасының җитештерүче - завод тарафыннан билгеләнгән хезмәт итү срогы артып киткән транспорт чараларының 10 таблицада күрсәтелгән өлеше түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$Д_{срок} = \frac{ЧТС_{факт\ срок > уст\ срок}}{ЧТС},$$

монда:

$ЧТС_{факт.срок.уст.срок}$ – даими маршрутлар буенча халыкка транспорт хезмәте күрсәтүгә җәлеп ителгән, факттагы эксплуатация срогы билгеләнгән хезмәт итү срогыннан артып киткән (капиталь ремонт вакытында хезмәт итү срогын арттыруны исәпкә алып) транспорт чараларының саны, данә;

ЧТС – даими маршрутлар буенча халыкка транспорт хезмәте күрсәтүгә җәлеп ителгән транспорт чараларының саны, данә.

Билгеләнгән хезмәт итү срогы артып киткән транспорт чараларының өлеше

10 таблица

| Билгеләнгән хезмәт итү срогы артып киткән транспорт чаралары өлешенең зурлыгы | Балл ($Д_{срок}$) |
|---|---|
| $< 10$ | 1 |
| $\geq 10$ | 2 |
| $\geq 20$ | 3 |
| $\geq 30$ | 4 |
| $\geq 40$ | 5 |
| $\geq 50$ | 6 |
| $\geq 60$ | 7 |
| $\geq 70$ | 8 |
| $\geq 80$ | 9 |
| $\geq 90$ | 10 |

6. Автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими йөртү маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда халыкка транспорт хезмәте күрсәтү сыйфатының дәрәҗәсе (КО) түбәндәге формула белән исәпләнә:

$$КО = \frac{Б_н}{Б_м} \times 100\% ,$$

монда:

Бк - әлеге методиканың 2-4 пунктларында билгеләнгән күрсәткечләргә бирелгән балларның суммасын кушып саналганнан соң җыелган баллар саны;

Би - максималь мөмкин булган баллар саны.

Исәп-хисап нәтиҗәләре буенча, әлеге методиканың 11 нче таблицасы зурлыклары нигезендә, автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими йөртү муниципаль маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда халыкка транспорт хезмәте күрсәтү сыйфаты турында нәтиҗә формалаштырыла.

Халыкка транспорт хезмәте күрсәтү сыйфатын бәяләү

11 таблица

| Хезмәт күрсәтүнең интервал зурлыклары КО | Автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими йөртү муниципаль маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең сыйфаты |
|---|---|
| $КО \leq 30\%$ | Канәгатьләнерлек түгел |
| $30\% < КО \leq 50\%$ | Минималь |
| $50\% < КО \leq 80\%$ | Уртача |
| $КО > 80\%$ | Югары |